

*Кол Гали*
(1183—1236)

Татар язма әдәбиятының мең еллык тарихы бар.Кол Галинең “ Кыйссаи Йосыф” поэмасы – борынгы әсәрләрнең берсе.Ул 1212-1233 еллар арасында иҗат ителгән.

Кол Гали үз заманының бик укымышлы кешесе булган.

Ул 1183 елда болгар җирендә, Зөя якларында туган.

Әдипнең чын исеме- Гали, “кол” сүзе аның кушаматы (псевдонимы) гына. Бу сүз алла колы (раб божий) дигән мәгънәне аңлата.

Халкыбыз күңелен сигез гасырга якын дулкынландырып килгән “Кыйссаи Йосыф” (“Йосыф китабы”) поэмасы болгар-татар язма әдәбиятының беренче үрнәкләреннән исәпләнә.Ул берничә йөз еллар дәвамында халкыбызның рухи дөньясын баетып килгән, сөендергән, моңландырган, елаткан,

өметләндергән, яшәргә көч биргән.Әсәр көйләп укылган, һәм шуның нәтиҗәсендә ул кешеләргә тирән тәэсир иткән,күңелләрен юаткан. Вакытында аны мәдрәсәдә уку китабы итеп тә файдаланганнар.

Күпчелек әсәрләрдә фәрештәләр, пәйгамбәрләр, һәм ”теге дөнья” гына сурәтләнгән заманда гади кеше образын да тудырган “Кыйссаи Йосыф” поэмасы укучыны (яки тыңлаучыны) үзенә җәлеп иткән. Автор геройларының төрлечә газаплануларын, хәсрәтләрен, күңел борчуларын, икеләнүләрен, бәхетле булу өчен көрәшүләрен тормышчан вакыйгалар, детальләр аша сурәтли. Кешегә начарлык эшләмә, мәрхәмәтле, игелекле, яхшы күңелле бул.Әсәрнең төп идеясе шуннан гыйбарәт.


# КАЗАН ШӘҺӘРЕНДӘ КОЛ ГАЛИ ҺӘЙ



# "КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫ ПАРКЫ" НДА КОЛ ГАЛИ ҺӘЙКӘЛЕНӘ ЧӘЧӘКЛӘР КУЮ. 8 СЕНТЯБРЬ 2005 ЕЛ




# УЛЬЯНДА КОЛ ГАЛИ ҺӘЙКӘЛЕНЕҢ АЧЫЛУЫ ЗУР ТАНТАНА






# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫ




**“КЫЙССАИ ЙОСЫФ” ПОЭМАСЫНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕ**

# ӘСӘРДӘН ӨЗЕК



# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ӘСӘРЕНЕҢ СЮЖЕТЫ

1. Йосыфның төше.
2. Йосыф коесының сыйфатлары.
3. Агаларының Йосыф янынннан кайтуы.
4. Дугыр улы Маликның төш күргәне.
5. Зөләйха турында бәян итү.
6. Даянең Зөләйхадан әхвәл соравы.
7. Зөләйханың гайбәтен сөйләгән хатыннар турында.
8. Кәнгъән гъәрәбе кыйссасы.
9. Йосыфның зинданнан чыгуы.
10. Йосыф вәзире кыйссасы.
11. Зөләйханы никях кылу.
12. Йагъкуб угъланнарының Мисырга баруы.
13. Йосыфның сарай салдыруы.
14. Йосыфның Йагъкубка күлмәген җибәрүе.
15. Мәлик Рәййанның Йагъкуб нәбине сараена чакыруы.
16. Йагъкубның Мисырдан китүе.
17. Йосыфның вафаты.

# ӘСӘРНЕҢ ТЕМАСЫ

Ягъкуб пәйгамбәр хәлләре һәм аның угылы
Йосыфның үз туганнары көнчелеге аркасында җәфа чигүе, авырлыкларны җиңә алуы, үч сакламау.
Саф мәхәббәт.

# ОБРАЗЛАР

1. Йосыф.
2. Зөләйха.
3. Йагъкуб.
4. Кыйтфир.
5. Ибне Йәмин.
6. Туганнары.
7. Аллаһ.

# ӘСӘРДӘ ПРОБЛЕМАТИКА

1. Тугрылык.
2. Сабырлык.
3. Ата белән бала мөнәсәбәте.
4. Кешелеклелек. Кеше бәхете.
5. Байлыкка кызыгу.
6. Ил белән гадел идарә итү.
7. Көнчелек.
8. Мәхәббәт.

# ӘСӘРДӘ ТӨШ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

1.”Туар кояш, тулган ай һәм 11 йолдыз
Барсы миңа төшемдә баш иде төп-төз.”
2.”Кояшның җиргә иңгәнен тордым күреп,
Ул якамнан чыкты, куенымнан кереп,
Энҗе-мәрҗән яуды җиргә яңгыр кебек,-
Мин аларны итәгемә җыйдым имди…”
3.”Төшемдә унбер бәти көтә идем,
Сакласам да берсен шунда җуя куйдым,
Кулларымнан бүре талап алды инде.”
4.”Җиде симез сыер күрдем, Һәркайсының сыртына мин менәр идем
Берсеннән берсенә күчәр идем,
Мондый төшкә мин аптырап калдым инде.”
5.”Шулай йоклап ята идем,
Төшемдә бер гаҗәп гүзәл сурәт күрдем
Уяндым да ул сурәтнең югын белдем,
Шул сәбәптән тыелалмый елыйм инде”

# ӘДӘБИЯТТА ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ КОЛ ГАЛИ ОБРАЗЫ

1. Р. Харис “Зөләйха” поэмасы.
2. Г. Әхмәтҗанов.” Кол Галиләр рухы”.
3. Н. Фәттах “Кол Гали” пьесасы.
4. “Кыйссаи Йосыф” балеты.
5. Казанда Кол Гали урамы.
6. Б. Урманчы, Т. Хаҗиәхмәтов, Ш. Әхмәдиев рәсемнәре.
7. Казан,Ульяндагы һәйкәлләр.

# КОЛ ГАЛИҺӘМ "КЫЙССАИ ЙОСЫФ"МӘҢГЕ БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛДӘ!

ЮНЕСКО карары белән 1983 елда Кол Галинең тууына 800, әсәре язылуга 750 ел тулу дөнья күләмендә билгеләп үтелде.

# ӘСӘРНЕҢ ИДЕЯСЕ

1.Ил белән акыллы, дөрес, сабыр, һәр яктан камил затлар идарә итәргә тиеш. Бары шунда гына халык төрле авырлыкларны, шул исәптән ачлыкны да җиңә ала.

2.Туганнар белән дус – тату яшәргә, туганлыкның кадерен белергә. 3.Чын бәхеткә кеше бары пакь вөҗдан, намус белән генә ирешә ала.

# ПОЭМАНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Кол Гали татар әдәбияты эчтәлегенә әхлак кануннарын кертә, шуның белән татар әдәбияты үсешенең үзәк юлын билгеле.

# СОҢГЫ СҮЗ

Кол Гали , моннан сигез гасыр элек яшәп,якты дөньядан киткән.Әмма аның хис – фикерләргә бай әсәре үлмәгән: ул халкыбыз белән бергә яшәгән, яши һәм яшәячәк. Бу – шагыйрь өчен иң зур бәхет.

Кол Гали - әдипләребезнең олуг остазы, укучыларыбызның мөхтәрәм шагыйре.